ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.12.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2366**

Зеленодольск шәһәре территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» 2020 елның 25 ноябрендәге 1062 номерлы карарын, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында «Яңа ел – 2020» бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү турында» 2020елның 3 ноябрендәге 2124 номерлы карарын үтәү йөзеннән, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның гомеренең һәм сәламәтлегенең, физик һәм юридик затларның, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның 20 декабреннән 2021 елның 10 гыйнварына кадәр Зеленодольск шәһәре территориясендә янгынга каршы махсус режим кертергә.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2020 елның 25 декабрендәге 1062 номерлы карарын үтәү өчен кабул итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә пиротехника әйберләрен саклау һәм сату шартларын мониторинглау комиссиясе составын расларга (№1 кушымта).
4. Зеленодольск муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлекләре Башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

үз җирлекләре территорияләрендә янгынга каршы махсус режим кертү турында карар кабул итәргә (әлеге карарга охшаш һәм җаваплы вазыйфаи затны күрсәтеп ). Шәһәр (авыл) җирлекләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында кабул ителгән карарларны 11.12.2020 елга кадәр ТР

буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә эштә исәпкә алу өчен җибәрергә.

5. 2021 елның 2 гыйнварыннан 10 гыйнварына кадәр гражданнар белән профилактик әңгәмәләр уздыруны оештыру максатында түбәндәге составта профилактик төркем төзергә:

– «ТР ЗМР ТКХ департаменты» МБУ әйдәп баручы белгече Камаев Сергей Александрович һәм хезмәт күрсәтүче оешма вәкилләре;

– ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге хезмәткәре (килешү буенча);

– Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге хезмәткәре(килешү буенча);

– ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең ДЯКХ ФЯКХ 8 федераль янгын сүндерү-коткару отряды хезмәткәре (килешү буенча);

– «ТР янгын сагы »ТР ДКУ хезмәткәре (килешү буенча);

– ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге хезмәткәре( килешү буенча);

– ЗМР БК опека һәм попечительлек бүлеге хезмәткәре;

– «Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика бүлекчәсенең Зеленодольск районара бүлеге хезмәткәре (килешү буенча);

– «Зеленодольскгаз " эксплуатация-җитештерү идарәсе хезмәткәре (килешү буенча);

– «Жилэнергосервис–Зеленодольск» ҖЧҖ һәм торак фондта электр хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче башка оешмалар хезмәткәрләре(килешү буенча) .

Профилактик әңгәмәләрне үткәргәндә күп балалы, имин булмаган гаиләләр һәм ялгыз карт гражданнарның яшәү урыннарына аерым игътибар бирергә кирәк.

6. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары-Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В.Афанасьевага , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.В.Лулаковка, «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы вазыйфаларын башкаручы Р. Р.Мөхәмәтдиновка, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы Л. В.Билалиевага , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы, Яшьләр эшләре бүлеге начальнигы О. А. Волчковага , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге начальнигы Д. А. Нигъмәтуллинга :

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә Яңа ел бәйрәме чараларын әзерләү һәм үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары комплексын гамәлгә ашырырга;

Яңа ел бәйрәме чараларын үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны янгынга каршы техник минимум программалары буенча укытуны оештырырга;

Яңа ел бәйрәм чараларын уздыру чорында кизү персоналы санын арттырырга;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең ябык биналарында ут эффектлары булган пиротехника әйберләрен саклауны һәм аларны куллануны рөхсәт итмәскә;

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре вакытында пиротехник эшләнмәләрне куллануны тыюга аерым игътибар биреп, балаларны куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтүне оештырырга.

7. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары начальнигы М. Г. Шакировка, Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге белән килештереп, Зеленодольск шәһәре территориясендә пиротехника әйберләрен сату урыннарында куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

8. Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге башлыгы полиция полковнигы А.Р. Ханбиковка Зеленодольск шәһәрендә Яңа ел һәм Раштуа чаралары үткәрү урыннарында хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

9. ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 8 нче янгын сүндерү – коткару гарнизоны башлыгы З. М.Хәлиуллинга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

бәйрәм чараларын үткәрү объектларында янгыннарны сүндерү планнарына һәм карточкаларына төзәтмәләр кертүне, шулай ук әлеге объектларда янгынга каршы су чыганакларын тикшерүне оештырырга;

пиротехника тамашасын уздыру вакытында куркынычсызлыкны тәэмин итәргә («Авангард» КСК, 31.12.2019, башлана 22:00).

10. ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы Р. Р. Ардыхановка түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын исәпкә алырга;

балалар катнашындагы Яңа ел һәм Раштуа тамашаларын үткәрү объектларына һәм урыннарына профилактик тикшерүләр үткәрергә;

пиротехника әйберләрен саклау һәм сату урыннарында профилактик эш алып барырга;

балаларның ял итү объектларына (туристлык һәм спорт базаларына, ял йортларына, санаторийларга, пансионатларга, ел әйләнәсендә ял итә торган сәламәтләндерү лагерьларына )профилактик тикшерүләр үткәрергә;

янгын чыгу очрагында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында бәйрәм чаралары уздыру объектларының хезмәт күрсәтүче персоналына инструктаж үткәрергә һәм янгын чыккан очракта аларның гамәлләрен эшләтеп карарга;

полиция хезмәткәрләре белән берлектә, моның өчен билгеләнгән сәүдә урыннарында, пиротехник эшләнмәләрне ачыклау һәм сатуны булдырмый калу буенча рейдлар оештырырга һәм үткәрергә.

11 ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 8 нче янгын сүндерү – коткару гарнизоны башлыгы З. М.Хәлиуллинга, ТР буенча Россия ГТХМ Баш

идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы Р. Р. Ардыхановка янгынга каршы махсус режим шартларында янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында халыкка хәбәр итүне оештыру тәкъдим итәргә.

12. «Зеленодольск РҮХ» ДАССОның баш табибы вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Мөхәммәтдиновка Яңа ел бәйрәм чараларын үткәрү урыннарында халыкка кирәкле медицина ярдәме күрсәтү буенча чаралар комплексын тормышка ашыруны тәкъдим итәргә.

13. Тәкъдим итәргә:

Зеленодольск шәһәре территориясендә пиротехника әйберләрен җитештерү, саклау һәм сату белән шөгыльләнүче юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә пиротехника әйберләрен сатканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын мәҗбүри үтәүне тәэмин итәргә;

Зеленодольск шәһәре территориясендәге автозаправка станцияләрен һәм комплексларын эксплуатацияләүче юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга, таләп ителә торган шартлау саклагычлары булмаган, территорияләрне һәм югарыда күрсәтелгән объектларның биналарын бизәгәндә электр гирляндаларын һәм башка иллюминацияне куллануны төшереп калдырырга;

Зеленодольск шәһәре территориясендә күпләп һәм ваклап сату белән шөгыльләнүче оешмалар җитәкчеләренә законнарда билгеләнгән тиешле сертификатлары (яраклылык декларацияләре) булмаганда пиротехника әйберләрен һәм электр гирляндаларын, шулай ук яңа ел бизәнү әйберләрен, ясалма чыршыларны техник документларда аларның янгын куркынычы күрсәткечләре һәм алар белән эш иткәндә янгын куркынычсызлыгы чаралары күрсәтелмәгәндә сатуны булдырмау чараларын күрергә ;

янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганаклары балансында булган предприятие һәм оешмалар җитәкчеләренә аларны төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә, шул исәптән янгын сүндерү машиналарын су чыганакларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук су чыганакларын кар һәм боздан чистартырга, янгын сүндерү өчен су белән тәэмин итү чыганакларына транспорт килү һәм керү урыннарын үз вакытында кардан һәм боздан чистарту эшен оештыруны;

гражданнарга пиротехник эшләнмәләрне санкцияләнмәгән куллану очраклары турында «112», «01», «02» ашыгыч оператив хезмәтләре телефоннары буенча, шулай ук башка мөмкин булган ысуллар белән җирле үзидарә органнарына хәбәр итәргә.

14. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Р.З. Хаҗиевка «Зеленодольская правда», «Наш Зеленый Дол.Зеленодольск» «Яшел Үзән» газеталары мөхәррирләре белән, «Татмедиа» «Зеленый Дол»мәгълүмат үзәге »ААҖ филиалы директоры белән бергә киңәшләшеп түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (.http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

Яңа ел бәйрәмнәрендә халык арасында янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм пиротехник эшләнмәләрдән файдаланганда янгын булган очракта, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәгәндә, үзеңне тоту буенча, шулай ук махсус янгынга каршы режим шартларында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен гражданнарның, юридик затларның административ җаваплылыгы турында киңәйтелгән пропаганда үткәрергә.

шәхси автотранспортны турыдан-туры янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары янында куярга ярамаганны халыкка хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына кушымта
08.12.2020 №2366

## Зеленодольск муниципаль районы территориясендә пиротехника әйберләрен саклауны һәм сату шартларын мониторинглау буенча комиссия составы

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Били торган вазифасы |
|---|---|---|
| 1. | Шакиров М. Г. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге начальнигы |
| 2. | Ардыханов Р. Р. | ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| 3. | Малыгин К. Е. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге полиция начальнигы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) (килешү буенча) |
| 4 | Агеева Е. К. | Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында «Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең территориаль бүлеге» начальнигы (килешү буенча) |